Республика Татарстан
Совет Альметьевского сельского поселения Сармановского муниципального района

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль районы
Әлмәт авыл җирлеге советы

КАРАР

РЕШЕНИЕ

28 февраль 2019 ел

№ 4

**Сарман муниципаль районы Әлмәт авыл җирлеге Советының 2016 елның 25 гыйнварындагы 5 нче номерлы «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы “Әлмәт авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге территориясендә гражданнарның үзара салымын җыю һәм куллану тәртибе турында Нигезләмә" карарына үзгәрешләр кертү турында»**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 56 статьясы һәм Сарман муниципаль районы Әлмәт авыл җирлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Әлмәт авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Әлмәт авыл җирлеге Советының 2016 елның 25 гыйнварындагы 5 номерлы «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы «Әлмәт авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә гражданнарның үзара салымын җыю һәм куллану тәртибе турында Нигезләмә» карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) нигезләмәнең исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Әлмәт авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге территориясендә гражданнарның үзара салым акчаларын куллану турында нигезләмә

2) "Үзара салым акчаларын җыю тәртибе"турындагы 5 нче кисәкне гамәлдән чыгарырга һәм муниципаль берәмлекнең аерым норматив хокукый акты белән билгеләргә.

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында " (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы «Сарман муниципаль районы»муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Сарман муниципаль районы Әлмәт авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

Әлмәт авыл җирлеге Советы рәисе Д.Ә.Газизов.